Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге Бибай Чаллысы авылында
Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 21 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 19 номерлы Әлки муниципаль районының «Иске Чаллы җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябендәге 18 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, 2019 елның 21 ноябрендәге 3 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске чаллы авыл җирлегендә халык җыены беркетмәсе нигезендә халык җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге составына керүче Бибай Чаллысы авылында гражданнар җыенын узган, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, 5 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләрдән тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

– авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш өю, торак пункт эчендәге юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кардан чистарту, чүплекләрне күмү) белән бәйле чыгымнарга - 220 сум;

- суэтем башняларын лицензияләү һәм эчәргә яраклы су анализын алу, су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, су башняларын коймалау һәм буяу белән бәйле чыгымнарга-120 сум;

- урам утларын урнаштыруга материал (яктырткычлар) сатып алуга, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләренә, урам яктыртуы энергиясе өчен түләүгә – 115 сум;

- балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру белән бәйле чыгымнарга-80 сум;

- чүп-чар өчен контейнерлар сатып алуга һәм контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә бәйле чыгымнарга һәм килешү буенча белгечләргә түләү – 65 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән; 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында

катнашучыларның тол хатыннары, 5 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

– авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш өю, торак пункт эчендәге юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кардан чистарту, чүплекләрне күмү) белән бәйле чыгымнарга - 220 сум;

- суэтем башняларын лицензияләү һәм эчәргә яраклы су анализын алу, су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, су башняларын коймалау һәм буяу белән бәйле чыгымнарга-120 сум;

- урам утларын урнаштыруга материал (яктырткычлар) сатып алуга, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләренә, урам яктыртуы энергиясе өчен түләүгә – 115 сум;

- балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру белән бәйле чыгымнарга-80 сум;

- чүп-чар өчен контейнерлар сатып алуга һәм контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә бәйле чыгымнарга һәм килешү буенча белгечләргә түләү – 65 сум;

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Чаллы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы: М. Г. Исхаков